**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**21 ноября 2023 г.** **№ 350**

**Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законы җитәкчелегендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруны тәртипкә салу һәм урнаштыру таләпләрен билгеләү максатларында, Биектау муниципаль район Советы

**КАРАР КЫРДЫ:**

1. Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. Биектау муниципаль районы Советының 2015 елның 27 июлендәге 463 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Биектау муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында муниципаль хокукый актлар эшләргә һәм кабул итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында - http://vysokaya-gora.tatarstan.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУга йөкләргә.

Совет председателе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов